ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 31 маенда
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $6^1$ статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә “Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы” сүзләрен “Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче” сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 өлештә “Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы” сүзләрен “Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче” сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

“$1^1$. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү түбәндәгеләргә карата үткәрелми:

1) муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы норматив хокукый актлар проектларына;

2) муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлар проектларына.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 10 маендагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

1. “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $6^1$ статьясы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) түбәндәгеләргә карата кулланыла:

1) Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә;

2) эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлегенә Татарстан Республикасы законы белән кертелгән шәһәр округларына (Казан шәһәре муниципаль берәмлегеннән тыш) һәм муниципаль районнарга;

3) башка муниципаль берәмлекләргә – “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 4 өлеше нигезендә эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгеләүче яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздырган очракта.

2. “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $6^2$ статьясы нигезләмәләре түбәндәгеләргә карата кулланыла:

1) Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә;

2) эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза уздыру мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлегенә Татарстан Республикасы законы белән кертелгән шәһәр округларына (Казан шәһәре муниципаль берәмлегеннән тыш) һәм муниципаль районнарга;

3) башка муниципаль берәмлекләргә – “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең икенче абзацы нигезендә эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза уздырган очракта.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 11 июне
№ 44-ТРЗ